Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлеге Иске Теләнче авылы

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«24» ноябрь, 2020ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Иске Теләнче авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2021 елда яшәү урыны буенчаЯңа Бүләк авыл җирлеге Иске Теләнче авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

- янгын сүндерү депосы төзү.

2. Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлеге Иске Теләнче авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларындаурнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлеге Иске Теләнче авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында«авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Бүләк авыл җирлеге Башлыгы М.С.Сагетдинов